ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.09.2026 г. Заинск № 461

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 21 маендагы 300 номерлы "Татарстан Республикасы Зәй районында урта һөнәри һәм югары белем бирү программалары буенча максатчан укыту турында Нигезләмәне раслау хакында" карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2026 елның 29 маендагы 640 номерлы «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 27 апрелендәге 555 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 21 маендагы 300 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй районында урта һөнәри һәм югары белемнең уку-укыту программалары буенча максатчан укыту турында Нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында урта һөнәри һәм югары белемнең уку-укыту программалары буенча максатчан укыту турында Нигезләмәнең 1 бүлегендәге 2 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«граждан» сүзен «Россия Федерациясе гражданы» сүзләренә алмаштырырга.;

« Россия Федерациясендә мәгариф турында «Федераль законда яисә Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы билгеләнмәгән булса» сүзләрен өстәргә.;

2. Әлеге карарны “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Р.Н. Камаловага йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы** **Р.М. Сәхәбетдинова**

Вәлиәхмәтова М.К.
9-90-19